Саттарова М.Р., ТГГПУ

# Татар сөйләшләрендә [$о^а$] фонемасы кулланылу

Татар теленең тарихын, үсешен өйрәнү төрки тел белемендә аерым урын алып тора. Язма истәлекләр, тарихи фактлар, археология, этнография кебек фәннәрнең тикшеренү нәтиҗәләре татар теленең бай үткәне булуын, аның башка төрки һәм төрки булмаган телләр белән күп гасырларга сузылган бәйләнешләрен раслый. Әлеге бәйләнешләр бүгенге татар теленең барлык ярусларында да чагылыш таба.

Күп гасырлар дәвамында татар халкы күрше фин-угорлар белән аралашып яшәгәнлеге билгеле. Әлеге бәйләнешләрнең фәнни өйрәнү объекты булуы да шуның белән нигезләнә.

Төрки–фин-угор телләре мөнәсәбәтләре күләмле тикшеренүләр таләп иткәнлектән, әлеге мәкалә кысаларында татар һәм марий телләре бәйләнешләренә күзәтү ясау максаты куела.

Генеологик яктан караганда, татар һәм марий телләре төрле гаиләләргә карый. Марий теле Урал телләре гаиләсенең фин-угор төркеме фин-идел тармагына карый. Аның татар теле белән күпмедер дәрәҗәдә уртаклыкка ия булуын чагыштырыла торган телләрнең Урал-Алтай телләр берлегенә каравы белән аңлатырга мөмкин. Татар һәм марий телләрен якынайта торган тагын бер күренеш – әлеге телләрнең шактый киң территориядә таралып урнашкан булуы. Төрки телләр кебек үк, фин-угор телләре дә Европадан алып Себер җирләренә кадәр таралган (венгр, саам, муром (үле), мерян (үле), финн, карел, эстон, марий, мордва, пермь, хантый, мансий, һ.б.).

Карала торган телләрдә, аралашу нәтиҗәсе буларак, охшаш билгеләр барлыкка килү бер үк дәрәҗәдә түгел. Тел үзенчәлекләреннән иң еш үзгәрешләргә дучар була торган лексика һәм чагыштырмача иң тотрыклы булган фонетик системаларны алып карасак, шактый кызыклы фикерләр туа.

Билгеле булганча, татар телендә [а] авазының берничә варианты кулланыла. Безнең очракта көчле иренләшү хас булган [$о^а$] авазы игътибарга лаек. Фонологик мәгънәгә ия булмаган әлеге аваз варианты беренче иҗектә

[о] авазына якын әйтелә. Мәсәлән, *о*$^{а}$*й* (месяц), *то*$^{а}$*л* (ива), *бо*$^{а}$*ш* (голова), *мо*$^{а}$*л* (скот), *о*$^{а}$*йо*$^{а}$*з* (ясный), *то*$^{а}$*лло*$^{а}$*рга*° (к ивам) и т.д. [Бурганова 1978: 56].

“Урта Идел һәм Урал буе татар халык сөйләшләре атласында” әлеге вариант махсус тамга белән бирелмәгән, бары кайсы торак пунктларда кулланылуы атласка комментарийларда әйтелеп үтелә [Комментарии 1989: 128-129]. Әлеге фонетик күренешнең таралу чикләре үзенчәлекле утрау булып, Атласның I томында гына билгеләнергә тиеш булган. Өч дистә авылны картага төшерсәк, [о$^{а}$] фонемасы кулланылышын билдергән изоглосса Шушма, Бура, Казансу һәм Мишәнең өске агымы, ягъни Татарстанның Мамадыш, Балтач, Саба, Арча, Кукмара һәм Киров өлкәсенең Малмыж районнарының өлешләрен үз эченә алачак.

Әлеге регионда [а] авазының уртача иренләшкән варианты да кулланыла һәм нык иренләшкән вариант соңрак формалашкан дип санала [Бурганова 1978: 57]. Әлеге фикерне раслау өчен Л.П.Грузов, М.Т.Матвеев кебек телчеләрнең фикерләрен дә искәртү кирәк. Алар марий теле олаштыручы характерга ия [Грузов 1965: 105–106; Матвеев 1960: 34] дип саный. Алда күрсәтелгән региондагы татар сөйләшләрендә нык иренләшкән [о$^{а}$] варианты кулланылу фин-угор субстраты белән бәйле дип уйларга урын бар. Казан арты, карала торган регион халкы элек-электән күрше фин-угор халкы – марий һәм удмуртлар белән аралашып яшәгән. Сирәк булса да гаилә бәйләнешләре дә юк түгел.

Чагыштыру өчен чуваш теле материалына да мөрәҗәгать итү уңышлы булыр. Чуваш теленең ике диалектында да [а] авазы гасырлар дәвамында үзгәреш кичергән. Югарыгы диалектта ул [о] авазына үзгәрсә (баш – *пос*, *саз* – *шор*, кара – *хора*, каз – *хор*), түбәнгесендә [у] (а>о>у) авазына күчкән (*пус, шур, хура, хур)* [Серебренников 1979: 54]. Әлеге күренеш чуваш теленең һәр диалекты формалашуда төрле компонентлар катнашканлыгын раслый. Югарыгы сөйләш вәкилләре фин-угор телле марийлар йогынтысын кичергән булып чыга.

Фин-угор-төрки телләр бәйләнешен раслау өчен марий теленең фонетик системасын өйрәнү дә кирәк. Чөнки, кискен чикләре булмаса да, башка фин-угор телләреннән, марий теленең тау һәм төньяк-көнбатыш сөйләшләреннән аермалы буларак, әлеге телнең көнчыгыш һәм болын диалектларында беренче иҗектәге [а] авазы урынына [о] кулланылу күзәтелә [Грузов 1965: 45]. Мәсәлән, мар., болын: *вож* (тамыр), *шопо* (ачы), *шоган* (суган), *кокыртыш* (какыру); мар., тау: *важ*, *шапы*, *шаган*, *кахыртыш*, мар.: *шочаш* (туу), *шордо* (поши), *пот* (казан), *йол* (аяк); эрзя-мордв.: *шачаш*, *шарды*, *пат*, *йал* һ.б. [Веске 1889: 34]. Бәхәсле фикерләрдән саналса да, әлеге үзгәрешләр Идел-Кама телләр берлеге өчен хас гомуми күренеш буларак каралырга да мөмкин. Фин-угор һәм төрки телле халыкларның Идел-Урал буйларында янәшә яшәве мең елдан артык тарихка ия [Халиков 1978: 36]. Бу факт Татарстан территориясендә сакланган һәм бүген дә актив кулланыла торган топонимнар белән дә раслана. Ашыт, Шушма, өлешчә Казансу бассейнында “ак чирмеш”, “чирмеш зираты”, “чирмеш ыруы”, “чирмеш ягы” һ.б. атамалар бар. *-ер, -енер, -енгер, -нур, -мар, -мер, -ма*га беткән авыл исемнәре дә шул хакта сөйли: Кенәр, Күңгәр, Мәңгәр, Урбар, Норма, Шүләңгер, Икшурма, Ушма, Шушма, Кукмара һ.б.

Марий телендә татар-төрки сүзләре кулланылуга инде күптән игътибар ителә. Г.Ф.Миллер, Ф.И.Сталенберг, Б.А.Серебренников, Р.Г.Әхмәтьянов, Исәнбаев һ.б. хезмәтләре шул хакта сөйли. Әлеге телләрнең лексик байлыгына күз салсак, шулай ук шактый кызыклы картина туа: ике телдә дә бер-берсеннән алынган сүзләр кулланыла, аерма аларның санында гына. Марий телендә аларның саны төрлечә - 650дән алып 1000гә кадәр дип билгеләнә. Ә татар телендә 20дән 70кә кадәр марий сүзе бар дип санала [Галкин 1992: 67]. Марий телендәге татар-төрки лексика кабул ителү чорларына (болгар, чуваш, татар теленнән, ягъни Алтын Урда, Казан ханлыгы чорына кадәрге һәм Көнчыгыш марийлар аерылганнан бүгенге көнгә кадәрге), тематик төркемнәргә бүлеп карала (аучылык, хуҗалык эшләре, төзелеш, техника, көнкүреш әйберләре атамалары һ.б.). Мәсәлән,

акташ, акыраш (акыру), алабута, алма, аргамак, бавурчак (бавырсак), зангар (зәңгәр), йашташ (яшьтәш), йемыш (җимеш), кыскыс (кыскыч), пезак (бизәк), тагармас (тәгәрмәч), тушман (дошман) һ.б.

Татар телендә марий сүзләре нигездә урманчылык, умартачылык һ.б. кебек тематикага карый. Мәсәлән, чәшке, поши, лапас, бүкән һ.б. [Әхмәтьянов 2001].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, әлеге регион татар сөйләшләре формалашуда фин-угор субстраты катнашкан һәм ул бүгенге көндә топонимнарда сакланган. Ә телнең фонетик системасына килгәндә, [а] авазының [о$^{а}$] варианты изоглоссалары әлеге регионда тирбәлеш зонасы барлыкка китерә. Топонимнар һәм фонетик системага караган дәлилләр элеккерәк бәйләнешләрнең характерын билгеләсә, лексикага караган фактлар, тизрәк үзгәрүчән булу сәбәпле, соңгырак контактларның табигате турында фикер йөртергә ярдәм итә. Татар теле тарихын ачыклауда әлеге юнәлеш кызыклы һәм катлаулы булуы белән алга таба да эзләнүләр таләп итә.

**Искәрмәләр**

1. Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья / Сост.: Ф.С.Баязитова, Н.Б.Бурганова, Л.Т.Махмутова и др. – Казань, 1989.

2. Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р.Г.Әхмәтьнов – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001. – 272 б.

3. Бурганова Н.Б. Из истории формирования фонетических особенностей татарских говоров Заказанья / Н.Б.Бурганова // Источниковедение и история тюркских языков. Казань, 1978. – 151 с.

4. Веске М. Исследование о наречии черемисского языка / М.Веске // Известия общ. арх., ист. и этнографии. Т. IV. Казань, 1889.

5. Галкин И.С., Патрушев Г.С. Русско-марийский словарь / И.С.Галкин, Г.С.Патрушев. – Йошкар-Ола, 1992.

6. Грузов Л.П. Фонетика диалектов марийского языка в историческом освещении / Л.П.Грузов. - Йошкар-Ола, 1965.

7. Исанбаев Н.И. Марийско-тюркские языковые контакты. Ч.1 / Н.И.Исанбаев. – Йошкар-Ола: Марийское книж. изд-во, 1989. – 173 с.

8. Комментарии к атласу татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья / Сост.: Ф.С.Баязитова, Н.Б.Бурганова, Л.Т.Махмутова и др. – Казань, 1989. – 300 с.

9. Матвеев Т.М. Краткий обзор чувашских диалектов (опыт районирования) / Т.М.Матвеев // МЧД, I. - Чебоксары: Чувашкнигоиздат, 1960. – 196 с.

10. Серебренников Б.А., Гаджиева Н.З. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков / Б.А.Серебренников, Н.З.Гаджиева. - Баку, 1979.

11. Халиков А.Х. Происхождение татар Поволжья и Приуралья / А.Х.Халиков. - Казань, 1978.